190

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Янгын куркынычсызлыгы турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасының бөтен территориясендәге торак пунктларында һәм объектларда янгын куркынычсызлыгын һәм янгыннан саклануны тәэмин итүнең гомуми хокукый, икътисадый һәм җәмгыяви нигезләрен билгели, янгынга каршы көрәш өлкәсендә вәкаләтле һәм башкарма хакимият органнары, милек рәвешләренә һәм шөгыльләренең төренә карамастан, предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар, шулай ук урындагы затлар һәм гражданнар арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала, янгыннан саклану хезмәткәрләрен хокукый һәм җәмгыяви яклауның гарантияләрен үз эченә ала.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Янгын куркынычсызлыгы һәм аны тәэмин итү нигезләре

1. Татарстан Республикасындагы янгын куркынычсызлыгы кешеләрнең, милек объектларының һәм матди байлыкларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә, техник яктан мөмкин һәм тиешле икътисадый дәрәҗәне тотып торуга юнәлгән хокукый, оештыру, икътисадый һәм фәннитехник чаралары системасыннан гыйбарәт.

2. Янгын куркынычсызлыгы түбәндәгеләр аркасында тәэмин ителә:

1/ янгынга каршы көрәштә законлылыкны ныгыту;

2/ икътисад өлкәсендәге объектларны янгыннан саклауга фәнни-

техник казанышларны, шартлау куркынычсызлыгы һәм янгын куркынычсызлыгы технологияләрен, матдәләрен һәм материалларын җәлеп итү;

3/ дәүләт органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар тарафыннан һәм урындагы затлар, гражданнар тарафыннан үз объектларында янгынга каршы чараларның үткәрелеше, шулай ук алар тарафыннан янгын куркынычсызлыгы нормаларының һәм кагыйдәләренең үтәлеше;

4/ янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге гомуми нигезләмәләрне, янгыннарга каршы көрәшкә халыкны оештыру тәртибен билгеләү, янгын куркынычсызлыгы чараларын халыкка өйрәтү;

5/ хокукый затларның һәм гражданнарның янгын куркынычсызлыгы нормаларын һәм кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыгы белән аларның янгын куркынычсызлыгы турында законнарны үтәүләре буенча икътисадый кызыксынуларын бергә алып бару;

6/ Дәүләт янгын күзәтүе һәм җәмәгать тикшерүе системасы.

<u>2 статья.</u> Янгын куркынычсызлыгының хокукый нигезләре

Янгын куркынычсызлыгының һәм янгыннан саклануның хокукый нигезе Татарстан Республикасы Конституциясеннән, әлеге Законнан, Татарстан Республикасының башка законнарыннан һәм хокукый актларыннан, дәүләт органнарының әлеге өлкәдә үз вәкаләтләре чикләрендә кабул иткән норматив актларыннан гыйбарәт.

Янгын куркынычсызлыгы һәм янгыннан саклану турында хокукый актлар кешеләрнең гомерен һәм сәламәтлеген, милли байлыкларны саклау һәм Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы эшләве максатларында янгынга каршы көрәш өлкәсендә хакимиятнең вәкаләтле һәм башкарма органнары, милек рәвешләренә, кемгә буйсынуларына һәм

шегыльләренең төренә карамастан, предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар, шулай ук урындагы затлар һәм граждан-нар арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салалар.

3 статья. Янгын куркынычсызлыгы нормалары һәм кагыйдәләре

1. Янгын куркынычсызлыгы нормалары һәм кагыйдәләре - янгын куркынычсызлыгы таләпләрен билгеләүче норматив актлар ул, аларны үтәү янгынга каршы халәтнең тиешле дәрәҗәсен тәэмин итә.

2. Янгын куркынычсызлыгы нормаларын һәм кагыйдәләрен дәүләтнең барлык органнары һәм җәмәгать берләшмәләре, милек рәвешләренә карамастан, барлык предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, шулай ук урындагы затлар һәм гражданнар үтәргә тиеш.

3. Республика территориясендә янгын куркынычсызлыгының уртак нормалары һәм кагыйдәләре гамәлдә була, аларны Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый.

4 статья. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсе һәм тикшерүе

1. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсе һәм тикшерүе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары һәм җирле администрация тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1/ янгыннан саклануны тәэмин итү өлкәсендә республика территориясендә дәүләтнең бердәм сәясәтен әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

2/ янгын куркынычсызлыгы турында Законны камилләштерүдә закон чыгару инициативасын күрсәтү;

3/ янгын хезмәтен, аның нәтиҗәлелеген, торак пунктларының һәм икътисад тармакларының янгынга каршы торышын арттыру буенча янгынга каршы төп техник гамәлләрне, бу өлкәдә фәнни-техник казанышларны үзләштерүне камилләштерү планнарын әзерләү, раслау һәм аларның тормышка ашырылуын тикшереп тору;

4/ Дәүләтнең янгын күзәтүенең нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү;

5/ янгыннан саклануның тармакара мәсьәләләрен хәл итү буенча министрлыкларның һәм ведомстволарның эшчәнлеген, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең, оешмаларның, шулай ук урындагы затларның һәм гражданнарның янгынга каршы комплекслы гамәлләр уздыру эшчәнлеген җайга салу.

<u>5 статья.</u> Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүче гамәлләрне башкарганда хезмәт коллективларының, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм гражданнарның катнашуы

Хезмәт коллективлары, янгынга каршы көрәшүчеләрнең ирекле берләшмәләре һәм башка берләшмәләр, шулай ук гражданнар гамәлдәге нормативлар нигезендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүче гамәлләрне башкаруда дәүләт органнарына ярдәм итәргә тиеш.

<u>2 бүлек.</u> Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнарының, предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең, оешмаларның, урындагы затларның һәм гражданнарның хокуклары һәм бурычлары

<u>6 статья.</u> Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә җирле үзидарә органнарының бурычлары

Җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләре чикләрендәге бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1/ янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүче гамәлләрне башкаруны

Совет территориясендә оештыру; янгыннан саклануны оештыру мәсьәләләрен хәл итү, дәүләт органнары белән бергә аңа кирәкле матди-техник нигез булдыру;

2/ Совет территориясендәге янгын куркынычсызлыгы халәтен даими карау, шуның белән бергә янгынга каршы тиешле гамәлләрне әзерләү, аларны торак пунктларының, милек рәвешләренә һәм кемгә буйсынуларына карамастан, предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның үсеше буенча икътисадый планнарында күз алдында тоту;

3/ янгыннарга каршы көрәштә халыкның актив катнашуын тәэмин итү, шул максатларда янгынга каршы көрәшүчеләрнең ирекле җәмгыятьләрен төзү, яшәү урыннарында халыкны янгын куркынычсызлыгы гамәлләренә өйрәтүне оештыру;

4/ колхозларның, совхозларның һәм башка предприятиеләрнең янгыннан саклану буенча ирекле хезмәте нигезендә, хуҗалык органнарының /милек рәвешләренә һәм кемгә буйсынуларына карамастан/ териле яклап исәпләнелгән түләүләре исәбенә, шулай ук җирле бюджет һәм гражданнардан кергән иганә исәбенә җирле администрация каршында янгыннан саклануның җирле хезмәтен оештыру.

<u>7 статья.</u> Урындагы затларның хокуклары һәм бурычлары

1. Министрлыкларның һәм ведомстволарның, предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең, оешмаларның, колхозларның һәм совхозларның җитәкчеләре түбәндәгеләргә хаклы:

1/ Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарыннан янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре турында тәкъдимнәр, киңәшләр һәм бәяләмәләр алырга;

2/ янгыннан саклануның объект бүлекчәләрен оештырырга;

3/ янгыннарның сәбәпләрен ачыклауга һәм үз объектларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар әзерләүгә янгыннан саклану белгечләрен җәлеп итәргә.

2. Министрлыклар һәм ведомстволар, предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар, колхозлар һәм совхозлар җитәкчеләренең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт;

1/ оештыру һәм инженер-техник чараларны әзерләү юлы белән икътисад тармакларының, үз ведомстволарына буйсынучы объектларның янгын куркынычсызлыгын, чыгарылган продукциянең норматив документларга туры килүен, шулай ук Дәүләтнең янгын күзәтүе органнары тарафыннан, милек рәвешләренә карамастан, объектларның тоткарлыксыз янгын-техник яктан тикшерелүен һәм янгыннарның тикшерелүен тәэмин итү;

2/ технологик процессларның, чыгарылган продукциянең янгын куркынычлылыгын киметүгә юнәлгән фәнни-техник казанышларны үзләштерүне тикшереп торуны һәм янгын вакытында кешеләрнең иминлеген тәэмин итүне оештыру;

3/ әзерләнүче стандартларга, паспортка, ведомство нормаларына, кагыйдәләргә, инструкцияләргә янгын куркынычсызлыгы өчен кирәкле таләпләрне кертү һәм объектларны проектлаганда, төзегәндә /үзгәртеп корганда/ һәм алардан файдаланганда аларның үтәлешен тикшерү;

4/ Дәүләтнең янгын күзәтүе күрсәтмәләрен /карарларын/ үтәү;

5/ эшчеләргә, инженер-техник хезмәткәрләргә, хезмәткәрләргә һәм колхозчыларга янгын куркынычсызлыгы чараларын өйрәтүне, хезмәт коллективлары әгъзаларын янгынны кисәтү һәм сүндерү эшләренә җәлеп итүне гамәлгә ашыру;

6/ янгын-техник комиссияләренең, янгыннан саклануның ирекле хезмәтенең, янгыннан саклану бүлекчәләренең, матди-техник нигезенең эшчәнлекләрен үзләренең вазыйфаларын уңышлы үтәрлек итеп оештыру һәм аларга юнәлеш бирү;

7/ янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте бүлекчәләренең кешеләренә зур янгыннарны сүндергәндә һәм беренче чираттагы һәлакәттән коткару эшләрен алып барганда ярдәмче көчләр һәм акча, ягулык-майлау материаллары, ашамлыклар һәм ял урыннарын билгеләнгән тәртиптә бирү /бюджет оешмаларыннан гайре/;

8/ янгыннан саклану буенча һәлакәттән коткару хезмәтенең "Янгын куркынычсызлыгы" исәп-хисабына төрле яклап исәпләнелгән түләүнең һәм төзелешнең норматив коэффициентының билгеләнгән күләмен күчерү.

8 статья. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә иминлек оешмаларының бурычлары

Янгыннардан иминлек гамәлләрен башкаручы оешмалар-янгыннардан иминлек өчен, шул исәптән, катнаш иминлек өчен дә алынучы түләүләрдән килгән керемнәрнең 20 проценты суммасында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүче чараларга һәм янгыннан саклану бүлекчәләренең сугышчан әзерлеген арттыруга акча кертергә, янгынга каршы стандартларның, нормаларның һәм кагыйдәләрнең таләпләрен үтәгән өчен иминлек аркасында кире кайтарылучы түләүләрне киметү рәвешендә иминлекне башкару ташламаларын билгеләргә, шулай ук, янгын чыгуга һәм /яисә/ аның нәтиҗәләренә иминлек кабул итүченең янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозуы яисә үтәмәве тәэсир иткән булса, иминлек өчен кире кайтарылучы түләүләрнең суммасын киметүне билгеләргә тиеш.

Иминлек түләүләре ташламаларын бирү, иминлек өчен кире кайтарылучы акчаларны киметү күләме һәм тәртибе иминлек кылынган

мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгы дәрәҗәсенә бәйле рәвештә гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

9 статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә гражданнарның хокуклары һәм бурычлары

1. Татарстан Республикасы гражданнары һәм республика территориясендәге башка республикаларның гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар түбәндәгеләргә хаклы:

1/ янгын очрагында гомерләрен, сәламәтлекләрен һәм милекләрен саклауга;

2/ аларның сәламәтлекләренә яисә милекләренә зыян китергән янгынның сәбәпләрен билгеләүдә катнашуга;

3/ Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарыннан янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләре хакында кирәкле киңәшләр алуга;

4/ янгын куркынычсызлыгы нормаларын һәм кагыйдәләрен бозулары аркасында янгын китереп чыгаруда гаепле предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар исәбенә янгыннан күргән зыяннарын түләттерүгә.

Зыянны түләү ирекле яисә хөкем карары нигезендә башкарыла.

2. Гражданнарның бурычлары:

1/ билгеләнгән тәртиптә расланган янгын куркынычызлыгы нормаларын һәм кагыйдәләрен җитештерүдә һәм көнкүрештә үтәү;

2/ Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарының урындагы затларына торак, ярдәмче һәм башка урыннарны, шулай ук җир кишәрлекләрен тикшерү мөмкинлеген булдыру;

3/ янгын чыгу очрагында янгыннан саклану хезмәтенә кичекмәстән хәбәр итү һәм кешеләрне, мөлкәтне коткару өчен, янгынны сүндерү өчен мөмкин гамәлләрне башкару.

3. һәр йорт, һәр ишегалды йорт хуҗасы исәбенә Татарстанның берләштерелгән җирле торак хуҗалыгы, шулай ук үз нисбәтендә торак фонды булган министрлыклары һәм ведомстволары раслаган исемлек нигезендә янгыннан саклану кораллары белән тәэмин ителергә тиеш.

10 статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә гражданнарның һәм хокукый мөнәсәбәтләрнең башка субъектларының хокукларын яклау

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, урындагы затларның кумәк һәм шәхси карарларына, шулай ук алар хокукый затларның һәм гражданнарның әлеге Законның 7, 9 статьяларында күрсәтелгән хокукларын бозучы гамәлләре турында буйсынуы буенча югарырак органнарга бер ай эчендә шикаять белдерергә яисә гамәлдәге законнарда күрсәтелгән тәртиптә һәм вакытта судка шикаять белдерергә мөмкин.

Шикаять бирү шикаять белдерелүче карарны һәм гамәлне туктатып тормый.

### 3 бүлек. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча гомуми таләпләр

II статья. Торак пунктларын планлаштыру һәм төзү

I. Торак пунктларын планлаштыру һәм төзү янгын куркынычсызлыгы ягыннан кешеләрнең тормышы һәм эшчәнлеге өчен аеруча уңайлы шартлар тудыруга туры килергә, торак секторын һәм мәдәният-көнкүреш объектларын янгыннан саклауның техник мәсьәләләрен төрле яклап хәл итүне күз алдында тотарга тиеш.

2. Шәһәрләрнең төп планнарын, торак пунктларын планлаштыруның һәм төзүнең проектларын, районны планлаштыруның проектларын

әзерләгәндә, гражданнарның, сәнәгатьнең һәм авыл хуҗалыгының объектларын урнаштыруны хәл иткәндә, төзелеш өчен җир кишәрлекләрен сайлаганда, шулай ук объектларны /сафка кертелә торган комплексларны/, корылмаларны, транспорт чараларын һәм инженер челтәрен проектлаштырганда, төзегәндә, үзгәртеп корганда һәм яңартканда янгын куркынычсызлыгының гамәлдәге нормалары һәм кагыйдәләре үтәлергә тиеш.

3. Төзелеш өчен җир кишәрлекләрен бирү, төзелеш /үзгәртеп кору, яңарту/өчен проект һәм норматив-техник документларны раслау, торак йортларны, мәдәният-көнкүреш биналарын һәм корылмаларын, сәнәгать, транспорт һәм башка предприятиеләрне /сафка кертелә торган комплексларны/ һәм корылмаларны файдалануга тапшыру аларның янгын куркынычсызлыгы нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килүләре турында Дәүләтнең янгын күзәтүе бәяләмәсе булганда гына рөхсәт ителә.

Янгыннан саклануның һәлак эттән коткару хезмәте бүлекчәләрендә янгын вакытында кешеләрне коткару өчен механик һәм башка техник чаралар булмаганда, кирәгеннән күбрәк катлары булган торак, җәмәгать һәм административ биналарны төзү һәм файдалануга тапшыру тыела.

4. Объектларны, биналарны һәм корылмаларны проектлау һәм төзү эшләрен үтәгән өчен җаваплы предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар янгын куркынычсызлыгы нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәмәгән очракта яисә аларны үтәү мөмкинлеге булмаганда, әлеге эшләрне башкаруны һәм аларны финанслауны Дәүләтнең янгын күзәтүе карары нигезендә туктатып торырга тиеш.

<u>12 статья.</u> Территорияләрне, биналарны һәм корылмаларны тоту

1. Торак пунктларының, предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/,

учреждениеләрнең һәм оешмаларның территорияләре тотылышы янгын куркынычсызлыгының гамәлдәге кагыйдәләренә туры килергә тиеш.

2. Торак пунктлары территорияләренең янгынга каршы тиешле халәтен тәэмин итүнең тәртибе һәм шартлары җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

<u>13 статья.</u> Торак урыннары

1. Гражданнарның вакытлыча яисә даими яшәү урыннары составлары, мәйданнары, урнашулары һәм җиһазланулары буенча алардан чыгу юлларының куркынычсызлыгын тәэмин итүче планлаштыру һәм конструкторлык карарларына туры килергә, янгын таралуга комачаулаучы техник чараларның эшкә әзер булуына һәм янучан продуктларның кергәнчә тотылуына җавап бирергә тиеш.

2. Торак биналарында һәм торак урыннарында администрация һәм фатир тотучылар тарафыннан янып китүчән матдәләрнең һәм материалларның дөрес сакланышын, янгын килеп чыгарлык эшләр башкарганда янгын куркынычсызлыгы гамәлләрен үтәүне, җайланмалардан һәм электр приборларыннан файдалануны тикшерү урнаштырылырга тиеш.

3. Предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар янгын куркынычсызлыгы нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килмәүче торак урыннарына урнашуны һәм яшәүне тыярга тиеш.

<u>14 статья.</u> Житештерү һәм җәмәгать биналарыннан, урыннарыннан, корылмаларыннан һәм җайланмалардан файдалану

1. Житештерү һәм җәмәгать биналарыннан, урыннарыннан, корылмаларыннан һәм җайланмалардан файдаланганда хезмәт, көнкүреш һәм ял өчен янгын куркынычсызлыгы ягыннан уңайлы шартлар тәэмин ите-

ләргә, янгын чыгуларны һәм таралуларны кисәтерлек гамәлләр кылынырга тиеш.

2. Предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар янгын куркынычсызлыгының билгеләнгән нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәмәгән очракта, Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарының карары нигезендә үзләренең эшчәнлекләрен яисә кайбер цехларының, участокларының эшен, биналардан, корылмалардан, транспорт чараларыннан файдалануларын, кайбер төр эшләрне башкаруларын һәм хезмәт күрсәтүләрен туктатып торырга яки туктатырга тиеш.

<u>I5 статья.</u> Транспорт чараларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү

Пассажирлар йөртү өчен билгеләнгән транспорт чараларының тезелешендә тиз янып китүчән һәм җылынган вакытта агулы матдәләргә таркалучан материалларны куллану рөхсәт ителми.

Пассажир транспорт чараларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында пассажирлар тарафыннан шартлау һәм яну куркынычлылыгы югары булган әйберләрне һәм матдәләрне йөртү тыела.

<u>I6 статья.</u> Урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү

Урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү таләпләре гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

<u>I7 статья.</u> Материаллар, матдәләр, әйберләр һәм икътисад тармакларының башка продукциясе, аларны әзерләү технологиясе

1. Үзләренең күрсәткечләре һәм сыйфатлары буенча икътисад тармакларының продукциясе аны җитештерү, ташу янгын куркынычсызлыгының гамәлдәге стандартларына, нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килергә тиеш.

2. Икътисад тармакларында һәм көнкүрештә файдалану өчен билгеләнгән яңа технологияләрне, материалларны, матдәләрне һәм әйберләрне җитештерүгә кертү, үзләштерә башлау һәм куллану аларның янгын куркынычсызлыгы стандартларына, нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килүләре хакында Дәүләт янгын күзәтүенең карары нигезендә генә рөхсәт ителә.

3. Янгын куркынычсызлыгының гамәлдәге стандартларына, нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килмәүче продукция чыгарган өчен җаваплы предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар Дәүләтнең янгын күзәтүе карары нигезендә шушы продукцияне җитештерүләрен яисә сатуларын туктатып торырга тиеш.

<u>I8 статья.</u> Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре турында махсус экспертизалар һәм консультацияләр

I. Фәнни-тикшеренү учреждениеләре һәм оешмалары, югары уку йортлары үз вәкаләтләре чикләрендә, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары кушуы буенча, шулай ук предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар гарызнамәләре буенча яңа кертелүче технологияләрнең, материалларның, матдәләрнең һәм әйберләрнең янгын куркынычсызлыгын бәяләүче махсус экспертизалар һәм консультацияләр үткәрергә тиеш.

2. Экспертиза һәм консультация үткәрүче учреждениеләр, оешмалар һәм белгечләр, фәнни-техник прогрессның хәзерге дәрәҗәсен исәпкә алып, экспертизаның сыйфаты, хаклыгы һәм тулылыгы өчен җавап бирәләр.

<u>I9 статья</u>. Эш һәм яшәү урыны буенча халыкны янгын-техник яктан әзерләү

Халыкны янгын-техник яктан әзерләү түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I/ янгын куркынычсызлыгы курсын уку программасына кертү юлы

белән мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә тәрбияләүдән, мәктәпләрдә һәм техник һөнәр училищеларында, югары һәм урта уку йортларында укытудан, икътисад тармаклары белгечләрен яңадан әзерләү һәм белгечлекләрен күтәргән вакытта өйрәтүдән;

2/ эшчәнлекләре шартлау-янгын чыгарлык җитештерү белән бәйле предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләрен, белгечләрен һәм башка хезмәткәрләрен һөнәри-техник әзерләүдән һәм аттестацияләүдән;

3/ гражданнарның яшәү урыннары буенча янгынга каршы әңгәмәләр, лекцияләр һәм инструктажлар үткәрүдән.

4 бүлек. Янгын куркынычсызлыгы турында законнарны бозган өчен җаваплылык

20 статья. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча җаваплылык

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм икътисад тармакларында, шулай ук, милек рәвешләренә, кемгә буйсынуларына карамастан, предприятиеләрдә /берләшмәләрдә/, учреждениеләрдә, оешмаларда, колхозларда һәм совхозларда янгыннарның профилактикасы буенча гамәлләрне башкару өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә йөкләнә.

Торак фатирларның, торак йортларның, каралтыларның һәм башка корылмаларның, дача һәм бакча өйләренең янгын куркынычсызлыгы халәте өчен җаваплылык аларның хуҗаларына йөкләнә.

21 статья. Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган яисә үтәмәгән өчен җаваплылык

Янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган яисә үтәмәгән өчен яки предприятиенең, җитештерү участогының, агрегатның эшен яисә бинадан, корылмадан, төзелмәдән файдалануны туктатып тору хакында

Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарының күрсәтмәләрен, карарларын үтәмәгән өчен предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең, оешмаларның, колхозларның һәм совхозларның урындагы затлары,шулай ук гражданнар гамәлдәге законнар нигезендә дисциплинар, административ һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.

Дәүләт милкенең һәм җирле милекнең торак фондындагы, шулай ук торак төзелеше кооперативларындагы торак урыннарында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган яисә үтәмәгән өчен җаваплылык аларның фатир тотучыларына йөкләнә, шәхси милек рәвешендә гражданнарныкы булган торак йортларда, ишегалды каралтыларында, дачаларда, бакча йортларында әлеге кагыйдәләр үтәлмәгән өчен җаваплылык аларның хуҗаларына йөкләнә.

22 статья. Дисциплинар җаваплылык

1. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган яисә үтәмәгән өчен предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затлары һәм хезмәткәрләре гамәлдәге законнарда каралган дисциплинар җәзага тартыла.

2. Предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләре Дәүләтнең янгын күзәтүе күрсәтмәсе буенча янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган урындагы затларга һәм шушы предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның хезмәткәрләренә дисциплинар җәза бирергә хаклы.

23 статья. Административ җаваплылык

1. Биналарда, корылмаларда, йортларда һәм алар тирәсендәге территорияләрдә, автотранспорт чараларында янгын куркынычсызлыгы стандартларын, нормаларын һәм кагыйдәләрен бозган яисә үтәмәгән өчен, шулай ук проектлаганда һәм төзегәндә төзелеш нормаларының һәм кагыйдәләренең янгынга каршы таләпләрен бозган өчен,-

кисәтү ясала яисә гражданнарга - ике минималь хезмәт хакы

күләменә кадәр, предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең, оешмаларның урындагы затларына - биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, хокукый затларга илле минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Административ җәза бирелгәннән соң бер ел эчендә кабатланган яисә янгын китереп чыгаруга сәбәп булган гамәлләр өчен, әгәр шушы гамәлләр җинаять җаваплылыгында күрсәтелмәгән булса,-

гражданнарга - биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең, оешмаларның урындагы затларына - икедән алып ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, хокукый затларга илледән алып йөз минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

2. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында Дәүләтнең янгын күзәтүе күрсәтмәләрен, агрегатны, участокны яисә тулысынча предприятиене эшләтүне, йорттан,бинадан, корылмадан файдалануны туктатып тору яки тыю турында Дәүләтнең янгын күзәтүе карарларын үтәмәгән өчен,-

гражданнарга - биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларына - икедән алып ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр, хокукый затларга илледән алып йөз минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

3. Әлеге статьяның 1,2 пунктларында күрсәтелгән, Дәүләтнең янгын күзәтүе тарафыннан салына торган штрафлардан килгән акчаларның 75 проценты - хокук бозылган урындагы бюджетка, ә 25 проценты "Янгын куркынычсызлыгы" хисабына кертелә.

24 статья. Җинаять җаваплылыгы

Янгын китереп чыгарырлык усал ният белән башкарылган яисә

саксыз гамәлләр өчен, әгәр шушы янгын аркасында кешеләр үлсә яисә аларның сәламәтлегенә зарар кылынса, зур зыян китерелсә яки алар башка авыр нәтиҗәләргә дучар ителсәләр, урындагы затлар һәм гражданнар гамәлдәге законнар нигезендә җинаять җаваплылыгына тартылалар.

25 статья. Янгын куркынычсызлыгы турында законнарны бозу аркасында китерелгән зыянны каплау

Предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар, колхозлар, совхозлар, шулай ук гражданнар янгын куркынычсызлыгы турында законнарны бозу аркасында китерелгән зыянны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә капларга тиеш.

Предприятиеләрне /берләшмәләрне/, учреждениеләрне һәм оешмаларны үзләре аркасында китерелгән зыянны каплау белән бәйле чыгымнарга дучар иткән урындагы затлар һәм башка хезмәткәрләр билгеләнгән тәртиптә матди җаваплы булалар.

Иминлек фирмалары, акционер иминлек компанияләре һәм башка иминлек төзелмәләре янгын чыгуда гаепле булганнарга түләтелгән иминлек суммасы күләмендә зыянны каплау турында дәгъва белдерергә хаклы.

5 бүлек. Татарстан Республикасының янгыннан саклану хезмәте

26 статья. Янгыннан саклану хезмәтенең максатлары һәм бурычлары

1. Татарстан Республикасында янгыннан саклану хезмәте гражданнарының гомерләрен һәм сәламәтлекләрен, матди һәм мәдәни байлыкларны янгыннан саклау максатларында оештырыла.

2. Янгыннан саклану хезмәтенең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I/ янгыннарны кисәтүгә юнәлгән гамәлләрне әзерләү, оештыру һәм тормышка ашыру, кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, торак пунктларының һәм объектларның янгыннан сакланышының нәтиҗәлелеген арттыру;

2/ торак пунктларында һәм объектларда янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткаруның беренчел эшләрен башкару.

3. Янгыннан саклану хезмәтенә башка бурычлар Закон тарафыннан гына йөкләнә.

27 статья. Янгыннан саклану хезмәтенең составы

Янгыннан саклану хезмәтенең составына түбәндәгеләр керә:

I/ янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте;

2/ янгыннан саклану буенча ведомство хезмәте;

3/ янгыннан саклану буенча ирекле хезмәт;

4/ янгыннан саклану буенча җәмагать оешмалары.

28 статья. Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте

Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте дәүләтнең янгыннан саклану буенча бердәм хезмәте ул, аңа түбәндәгеләр керә:

I/ Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгыннан саклану буенча һәлакәттән коткару хезмәте;

2/ янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтенең хәрбиләштерелгән һәм хәрбиләштерелмәгән бүлекчәләре;

3/ шушы хезмәткә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен төзелгән башка бүлекчәләр.

2. Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте янгынга каршы стандартларның, нормаларның һәм кагыйдәләрнең таләпләрен үтәү буенча дәүләт күзәтүен гамәлгә ашыра; янгыннарны

сүндерүне һәм үзендә булган барлык көч-куәтләрне һәм чараларны җәлеп итеп, һәлакәттән коткару буенча беренче чираттагы эшләрне башкаруны оештыра һәм тәэмин итә; торак пунктларын һәм объектларны саклау буенча янгынны кисәтүче гамәлләрне билгеләнгән тәртиптә әзерли.

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте турында нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

3. Бүлекчәләрдә хезмәт итүнең тәртибе һәм шартлары "Эчке эшләр органнарында хезмәт итү турында нигезләмә" тарафыннан һәм хезмәт турындагы законнар нигезендә җайга салына; әлеге бүлекчәләрнең эшчәнлеге янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте турындагы уставлар һәм өйрәтмәләргә туры китереп оештырыла.

29 статья. Дәүләтнең янгын күзәтүе

I. Дәүләтнең янгын күзәтүе республикадагы янгын куркынычсызлыгының югары дәрәҗәсен тоту, әлеге Законның һәм янгын куркынычсызлыгы турында норматив актларның үтәлешен тикшереп тору өчен гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләтнең янгын күзәтүе, билгеләнгән бурычларны үтәү йөзеннән, түбәндәгеләрне башкара:

I/ сайлап алып, кирәк чагында яисә гарызнамәләр буенча министрлыкларның, ведомстволарның, предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең, оешмаларның һәм гражданнарның әлеге Законны, янгын куркынычсызлыгы турында, янгыннарны кисәтүгә, янгын килеп чыкканда, кешеләрнең иминлеген тәэмин итүгә юнәлгән башка норматив актларны үтәүне күзәтә;

2/ республикадагы янгын куркынычсызлыгы халәтен анализлый

һәм аның нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына тәкъдимнәр кертә;

3/ кызыксынган органнар һәм оешмалар белән бергә янгын куркынычсызлыгының республика нормаларын һәм кагыйдәләрен эшли;

4/ предприятиеләрне, биналарны һәм корылмаларны проектлаганда, төзегәндә һәм үзгәртеп корганда, каралган нормаларның һәм кагыйдәләрнең янгынга каршы таләпләренең проектлаучы һәм төзелеш оешмалары тарафыннан үтәлешен тикшереп тора;

5/ төзелеп беткән объектларны файдалануга тапшыру комиссияләренең эшендә катнаша һәм объектны файдалануга тапшыру мөмкинлеге хакында бәяләмә бирә;

6/ янгыннар турындагы һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозулар хакындагы эшләр буенча сорау алулар уздыра;

7/ республикадагы янгынга каршы ирекле хезмәтнең ныгуына ярдәм итә, ирекле янгынчылар җәмгыятенең республика советы белән берлектә, янгынга каршы пропаганда һәм агитация буенча тиешле гамәлләр башкара, янгынга каршы көрәш турында техник әдәбият, кинофильмнар, телевидение тапшырулары, чыгаруны, янгыннарны кисәтү һәм сүндерү мәсьәләләре турында массакүләм матбугат чараларында хәбәрләр бирүне оештыра;

8/ укучыларга һәм студентларга янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен өйрәтүне яхшырту, массакүләм һөнәр эшчеләрен һәм хезмәткәрләрен әзерләү системасында әлеге мәсьәләләрне өйрәтү, җитәкче кадрларның белгечлеген күтәрү һәм яңадан әзерләү буенча тәкъдимнәр эшләү белән кызыксынган министрлыкларга һәм ведомстволарга, халык мәгарифенең республика органнарына ярдәм күрсәтә;

9/ янгын автоматикасының бергә кушылган җайланмалары эшен берләштерә һәм анализлый, аларның ышанычлылыгын һәм нәтиҗәлеле-

ген арттыру турында тәкъдимнәр кертә;

10/ иминлек фирмалары белән берлектә иминлек түләүләре буенча ташламалар бирүнең, янгыннан саклану буенча тәэмин ителешенә һәм иминләнгән милекнең янгын куркынычсызлыгы халәтенә карап, иминлек түләүләрен кире кайтаруның күләмнәрен һәм тәртибен билгели;

11/ продукцияне янгын куркынычсызлыгы нисбәтеннән әзерләүче, сынаучы һәм рөхсәт бирүне хуҗалык исәбендәге оешмаларга һәм бүлекчәләргә махсус рөхсәт кәгазьләре /лицензияләр/ бирә, рөхсәт кәгазьләрен /лицензияләрне/ бирү һәм кире алу тәртибен билгели;

12/ кызыксынган министрлыклар, ведомстволар, оешмалар белән килешеп, милек рәвешләренә һәм кемгә буйсынуларына карамастан, янгыннан саклану хезмәтенең бүлекчәләрен һәм янгын сүндерү, табигый бәла-казалардан килгән зыянны бетерү өчен янгын сүндерүчеләрнең ирекле төзелмәләрен җәлеп итү тәртибен билгели;

13/ янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм "Янгын куркынычсызлыгы" хисабына акча кертүче янгыннан саклану хезмәтен нәтиҗәле оештыру өлкәсендә предприятиеләргә /берләшмәләргә/, учреждениеләргә, оешмаларга һәм гражданнарга билгеләнгән тәртиптә түләүле хезмәт күрсәтә.

<u>30 статья.</u> Дәүләт янгын күзәтүенең урындагы затлары һәм аларның вазыйфалары

1. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте башлыгы - Татарстан Республикасының янгын күзәтүе буенча дәүләтнең баш инспекторы да, эш урыны буенча ул Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрының урынбасары да була.

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтенең башлыгын Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасының Премьер-министры билгели.

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте башлыгының урынбасарлары Татарстан Республикасының янгын күзәтүе буенча дәүләтнең баш инспекторы урынбасарлары да булалар.

Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтенең бүлек һәм бүлекчәләре башлыклары, янгыннан саклану отрядларының һәм частьләренең башлыклары һәм аларның урынбасарлары эш урыннары ягыннан бер үк вакытта янгын күзәтүе буенча дәүләтнең өлкән инспекторлары да булалар.

2. Янгын күзәтүе буенча дәүләтнең баш инспекторы һәм аның урынбасарлары түбәндәгеләргә хаклы:

1/ янгынга каршы гамәлдәге нормалардан һәм кагыйдәләрдән тайпылулар, шулай ук нормаларны һәм кагыйдәләрне үтәмәүче төзелеш объектларын проектлауның хәл ителеше турында бәяләмәләр бирергә;

2/ янгын чыгарлык хәлдә булган предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшен туктатып торырга яисә тыярга, янгын куркынычсызлыгы стандартлары таләпләренә туры килмәүче продукцияләрне җитештерүне тыярга;

3/ янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләре турындагы стандартларны, техник шартларны килештерергә;

4/ әлеге Законның 2I статьясында күрсәтелгән хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм кисәтү яисә штраф рәвешендә административ җәза бирергә: гражданнарга – биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр; предприятиеләрнең /берләшмәләр-

нең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларына – ун минималь хезмәт хакы күләменә кадәр; хокукый затларга – йөз минималь хезмәт хакы күләменә кадәр.

3. Янгын күзәтүе буенча дәүләтнең өлкән инспекторы һәм аның урынбасарлары түбәндәгеләргә хаклы:

1/ янгын чыгарлык хәлдә булган предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эшен өлешчә туктатып торырга, шундый ук хәлдәге биналардан һәм корылмалардан файдалануны тыярга;

2/ җирле проект оешмалары тарафыннан проектлар әзерләнгәндә гамәлдәге нормалардан һәм кагыйдәләрдән тайпылулары хакында бәяләмәләр бирергә;

3/ әлеге Законның 2I статьясында күрсәтелгән хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм Дәүләтнең янгын күзәтүе органнары исеменнән кисәтү яисә штраф рәвешендә административ җәза бирергә:

гражданнарга – өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр;

предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларына – җиде минималь хезмәт хакы күләменә кадәр;

хокукый затларга – илле минималь хезмәт хакы күләменә кадәр.

4. Янгын күзәтүе буенча дәүләт инспекторы түбәндәгеләргә хаклы:

1/ аерым биналардан файдалануны тыярга; әгәр предприятиенең тулысынча эшен туктатырлык булмаса, җитештерү участогының яисә җайланманың эшен туктатып торырга;

2/ әлеге Законның 2I статьясында күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга һәм кисәтү яисә штраф рәвешендә административ җәза бирергә:

гражданнарга - ике минималь хезмәт хакы күләменә кадәр;

предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларына - биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр.

5. Дәүләт янгын күзәтүенең барлык урындагы затлары түбәндәгеләргә хаклы:

1/ милек рәвешләренә карамастан, объектларның янгын-техник халәтен теләсә кайсы вакытта /торак урыннарыннан гайре/ тикшерергә; шулар нәтиҗәсендә предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар үтәргә тиешле янгын куркынычсызлыгы турындагы норматив актларны бозуларны бетерерлек күрсәтмәләр һәм язулар бирергә;

2/ үзенә буйсынучы янгын бүлекчәләренең һәм ирекле янгын төзелмәләренең эшчәнлеген тикшереп торырга, тикшерү нәтиҗәләре буенча эшчәнлекләрендәге җитешсезлекләрне бетерү турында һичшиксез үтәлергә тиешле күрсәтмәләр һәм актлар чыгарырга;

3/ предприятиеләрдән /берләшмәләрдән/, учреждениеләрдән, оешмалардан, колхозлардан, совхозлардан һәм гражданнардан янгын куркынычсызлыгы халәтен чагылдыручы белешмәләр һәм документлар таләп итәргә;

4/ фатир хуҗасы яисә торак урыннары һәм ярдәмче каралтылар хуҗасы ризалык бирмәгәндә, шәһәр /район/ прокуроры рөхсәте /санкциясе/ нигезендә фатирларны, шәхси йортларны, тулай торaклардан һәм кунакханәләрдән тыш, башка торак урыннарын тикшерергә, шулай ук гражданнар милкендәге дачаларны, гаражларны һәм башка ярдәмче каралтыларны тикшерергә.

31 статья. Дәүләт янгын күзәтүенең урындагы затлары җаваплылыгы

Дәүләт янгын күзәтүенең урындагы затлары гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләр өчен җаваплы булалар:

янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозулар һәм янгыннар турындагы эшләр буенча тикшерү һәм сорау алулар башкарганда, шулай ук Дәүләтнең янгын күзәтүе органнары биргән хокуклардан файдаланганда, административ һәм гамәли җинаять законнарының үтәлеше өчен;

яңа төзелешләрнең, биналарның һәм корылмаларның проект документациясе нормаларында һәм кагыйдәләрендә каралган янгынга каршы гамәлдәге таләпләргә туры килерлек экспертиза уздыру өчен;

Дәүләт янгын күзәтүенең бәяләмәләрен һәм күрсәтмәләрен вакытында һәм сыйфатлы рәсмиләштерү өчен.

32 статья. Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарының урындагы затлары гамәлләренә шикаять белдерү

1. Штраф рәвешендә административ җәза бирү турындагы эш буенча чыгарылган карар хакында шикаять югарырак урындагы затка яисә район /шәһәр/ судына бирелә, хөкем карары катгый була.

2. Дәүләтнең янгын күзәтүе органнарының урындагы затлары гамәлләре /битарафлыклары/ турындагы шикаятьләрне һәм гаризаларны карау гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта башкарыла.

Шикаять белдерү шикаять белдерелгән әлеге гамәлләрне туктатып тормый.

33 статья. Янгыннан саклануның ведомство хезмәте

Янгыннан саклануның ведомство хезмәте янгыннарны кисәтү һәм сүндерү өчен милекчеләр тарафыннан төзелгән органнар һәм бүлек-

чәләрдән гыйбарәт.

Тимер юл,һава юлы һәм елга транспорты, Татарстан Республикасының Дәүләт иминлек комитеты, Татарстан Республикасы территориясендәге Россия Федерациясенең Оборона министрлыгы объектларын янгыннан саклау хезмәте үзенең эшчәнлеген шушы төр саклануларның әлеге Закон нигезендә эшләнгән ведомство нигезләмәләренә туры китереп оештыра һәм гамәлгә ашыра.

Милек рәвешләренә, кемгә буйсынуларына һәм шөгыльләренең төренә карамастан, башка предприятиеләр/берләшмәләр/, учреждениеләр һәм оешмалар янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте биргән рөхсәт нигезендә янгыннан саклануның /янгыннан саклауның/ хәрбиләштерелмәгән бүлекчәләрен төзергә хаклы.

Янгынга каршы кучмә техникасы булган янгыннан саклануның ведомство хезмәте бүлекчәләре янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтендә хисапка алыналар һәм янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте билгеләгән тәртиптә янгын сүндерү, һәлакәттән коткаруның беренчел эшләренә җәлеп ителәләр.

Янгыннан саклануның ведомство хезмәте бүлекчәләре янгыннарны сүндерүне һәм хезмәткәрләрен әзерләүне оештыру мәсьәләләрендә янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте уставларына һәм өйрәтмәләренә таяналар.

<u>34 статья.</u> Янгыннан саклануның ирекле хезмәте

Янгыннан саклануның ирекле хезмәте авыл торак пунктларында, объектларда оештырыла һәм билгеләнгән тәртиптә расланган һәм теркәлгән уставлар /нигезләмәләр/ нигезендә үз вазыйфаларын башкара.

35 статья. Янгыннан саклануның җәмәгать оешмалары

Янгыннан саклануның җәмәгать оешмалары /җәмгыятьләр, берлекләр, берләшмәләр, фондлар һәм б.ш./ законда билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән һәм теркәлгән гамәлгә кую документлары нигезендә төзеләләр һәм үз эшчәнлекләрен алып баралар.

6 бүлек. Янгыннан саклану хезмәте хезмәткәрләрен хокукый һәм җәмгыяви яклауның гарантияләре

36 статья. Янгын сүндерү җитәкчесенең хокуклары

1. Янгын сүндерү җитәкчесе бердәнбер башлык була, аңа янгын яисә һәлакәт булган урындагы бөтен кешеләр дә, барлык чаралар да буйсына.

Урындагы затларның берсе дә аның гамәлләренә тыкшынырга яисә аңа янгын сүндергәндә һәм һәлакәттән коткаруның беренчел эшләрен башкарганда аның кешеләр һәм чаралар белән идарә итү турындагы боерыкларын юкка чыгарырга хаклы түгел.

Янгын сүндерү җитәкчесенең законлы таләпләрен дәүләтнең барлык органнары, предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар, урындагы затлар һәм гражданнар һичшиксез үтәргә тиеш.

2. Янгын сүндерү җитәкчесе түбәндәгеләргә хаклы:

1/ милек рәвешләренә, нинди ведомствога буйсынуларына һәм шөгыльләренең төренә карамастан, һәлакәттән коткаруның кирәкле хезмәтләрен янгыннарны сүндерүгә һәм һәлакәттән коткаруның беренчел эшләрен башкаруга җәлеп итәргә;

2/ янгын, һәлакәт зонасында объектларның, кайбер җитештерүләрнең, участокларның, агрегатларның эшен туктатып тору һәм җайланмаларны сүндереп тору турында үтәлүе мәҗбүри булган боерыклар бирергә;

3/ янгын чыккан яисә һәлакәткә тарган объектның урындагы затларыннан объектның планы, үзенчәлекләре, анда булган куркыныч матдәләр һәм материаллар турында мәгълүматлар таләп итәргә һәм алырга.

3. Янгыннарны сүндерү һәм һәлакәттән коткаруның беренчел эшләрен башкару өчен предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр һәм оешмалар янгын сүндерү җитәкчесенең таләбе буенча үз карамагындагы кешеләрне, шулай ук янгын сүндерү, су ташу, төзелеш һәм башка техниканы, җайланмаларны, янгын сүндерүче матдәләрне һәм материалларны биреп торырга тиеш.

Кешеләрне, янгын сүндерүче чараларны, техниканы һәм җайланмаларны биреп тору тәртибен җирле администрация җайга сала.

<u>37 статья.</u> Янгыннан саклану хезмәте хезмәткәрләренең янгын сүндергәндә һәм һәлакәттән коткаруның беренчел эшләрен башкарганда төп хокуклары

1. Янгыннан саклану хезмәте хезмәткәрләре янгын сүндергәндә һәм һәлакәттән коткаруның беренчел эшләрен алып барганда бары тик үзләренең турыдан-туры башлыкларына гына буйсыналар.

Янгын сүндерү һәм һәлакәттән коткару эшләрен башкарганда, закон нигезендә вәкаләтле затлардан гайре, беркем дә аларның эшчәнлегенә тыкшына алмый.

Янгыннан саклану хезмәтенең хезмәткәрләрен әлеге Законда янгыннан саклану хезмәтенә йөкләнмәгән вазыйфаларны һәм эшләрне үтәргә беркем дә мәҗбүр итәргә хаклы түгел.

2. Янгын сүндергәндә һәм һәлакәттән коткаруның беренчел эшләрен башкарганда янгыннан саклану хезмәте хезмәткәрләре түбәндәгеләргә хаклы:

1/ тәүлекнең теләсә кайсы вакытында янгын һәм янучан әйберләр таралган һәм таралырга мөмкин булган җитештерү урыннарына,

торак һәм башка урыннарга каршылыксыз керергә, кирәк чакта бикле тәрәзәләрне һәм ишекләрне ачарга, шулай ук, кешеләрне коткару, янгынны сүндерү өчен кирәк булганда, койма рәвешендәге тезелмәләрне ачарга;

2/ урамнарда һәм юлларда, транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен, шулай ук гражданнарның шушы урындагы кайбер участокларга яисә объектларга кереп йөрүләрен вакытлыча чикләргә яисә тыярга, янгын сүндерү һәм ул китергән зыянны төзәтү, шәхес һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү эшләре башкарыла торган кайбер урыннардан гражданнарны чыгарып торырга;

3/ дәүләт органнарыныкы, предприятиеләрнеке /берләшмәләрнеке/, учреждениеләрнеке, оешмаларныкы һәм гражданнарныкы булган элемтә чараларыннан кичектергесез очракларда каршылыксыз һәм бушлай файдаланырга, шулай ук алар ризалыгы белән, гамәлдәге законнарда билгеләнгән шартларда янгын сүндерү һәм һәлакәттән коткаруның беренчел эшләрен башкару өчен кирәкле башка мөлкәттән файдаланырга;

4/ кичектергесез очракларда, үзләренең кешеләрен җыяр өчен, кичектергесез табиб ярдәменә мохтаҗ затларны дәвалау учреждениеләренә илтеп җиткерү өчен дипломатиянеке, консуллыкныкы һәм чит илләрнең, халыкара оешмаларның башка вәкилиятләренеке булмаган транспорт чараларыннан файдаланырга.

<u>38 статья.</u> Ирекле янгын сүндерүчеләрнең җәмгыяви яклауның һәм эшчәнлекләрен хуплауның гарантияләре

Янгыннан саклануның ирекле хезмәте эшендә гражданнарның катнашуы мактаулы җәмәгать эшеннән санала.

Ирекле янгын сүндерүчеләргә янгын сүндерү, һәлакәттән коткару эшләрен график буенча башкарганда, шулай ук янгыннарны,

һәлакәтләрне һәм афәтләрне кисәткәндә һәм янгыннардан, һәлакәтләрдән һәм афәтләрдән килгән зыяннарны төзәткәндә янгынга каршы ирекле төзелмәләрдә сугышчан кизү торган вакыт өчен төп эш урынындагы уртача айлык хезмәт хакы күләмендә акча түләнә.

Ирекле янгын сүндерүчеләрнең хезмәт хакына һәм матди бүләкләүләрнең башка төрләренә салым салынмый.

Янгыннан саклануның хәрбиләштерелгән хезмәте эшләмәгән торак пунктларындагы янгынга каршы ирекле төзелмәләрнең сугышчан кизүләрендә катнашучы ирекле янгын сүндерүчеләр өйләрендә чиратсыз телефон куйдырырга хаклы.

39 статья. Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте хезмәткәрләренең һөнәри берлекләргә /берләшмәләргә/ берләшү хокукы

Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте хезмәткәрләре, үзләренең һөнәри, җәмгыяви-икътисадый һәм башка хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау йөзеннән, һөнәри берлекләргә /берләшмәләргә/ берләшергә яисә керергә хаклы. Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте хезмәткәрләренең һөнәри берлекләрен /берләшмәләрен/ төзү һәм аларның вәкаләтләре тәртибе гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

Күмәк хезмәт бәхәсен хәл итү рәвешендә янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте хезмәткәрләренең эш ташлаулары тыела.

40 статья. Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте хезмәткәрләренә бирелүче ташламалар

Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтенең махсус исемнәр бирелгән башлыклары эчке эшләр органнарының хезмәткәрләре өчен гамәлдәге законнарда билгеләнгән ташламалардан файдаланалар.

41 статья. Тәвәккәллек өчен түләү

Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте башлыгы һәм шуңа вәкаләтле башка урындагы затлар янгын сүндергәндә, яисә һәлакәттән коткару эшләрен башкарганда, үз гомерләрен дә кызганмыйча, сугышчан бурыч үтәгән гражданнар өчен тәвәккәллек өчен бер мәртәбә бирелә торган түләү билгеләргә хаклы. Мондый төр түләүне куллану тәртибен Татарстан Республикасының Эчке эшләр министрлыгы билгели.

Җирле үзидарә органнары җирле бюджет исәбеннән янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте хезмәткәрләренә бирү өчен, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгәннәрдән тыш, өстәмә түләүләр билгели ала.

42 статья. Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте хезмәткәрләренең транспорттан бушлай файдалануылары

Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте хезмәткәрләре үзләренең вазыйфаларын башкарганда - шәһәр, район транспортының һәм җирле транспортның /таксидан гайре/ һәр төреннән, ә авыл җирендә - юлында очраган транспорттан бушлай файдалана алалар, шулай ук янгын сүндерергә, һәлакәтләр, афәтләрдән килгән зыяннарны төзәтергә яисә аларны тикшерергә баручы хезмәткәрләр һава, тимер юл, елга һәм автомобиль транспортына чиратсыз билет алырга хаклы.

Эшендә шәхси транспортыннан файдаланган хезмәткәрләргә билгеләнгән күләмдә акчалата компенсация түләнә.

7 бүлек. Янгыннан саклану хезмәтен финанслау һәм матди-техник яктан тәэмин итү

43 статья. Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте эшчәнлеген финанслау

1. Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте эшчәнлеген финанслау түбәндәгеләр исәбеннән башкарыла:

1/ Татарстан Республикасы бюджетыннан;

2/ җирле бюджетлардан;

3/ янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтен финанслау өчен шартнамә нигезендә федераль бюджеттан килгән акчалар;

4/ билгеләнгән тәртиптә төзелгән шартнамәләр нигезендә предприятиеләрдән /берләшмәләрдән/ учреждениеләрдән һәм оешмалардан керүче акчалар;

5/ төрле милек рәвешләрендәге /бюджет оешмаларыннан тыш/, үзенең объектларын янгыннан саклаучы күчмә техникасы булмаган предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең һәм оешмаларның янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтен тоткан өчен төрле яклап исәпләнелгән түләүләре;

6/ милек рәвешләренә, нинди ведомствога буйсынуларына һәм шөгыльләренең төрләренә карамастан /бюджет оешмаларыннан гайре/, объектларны төзү һәм үзгәртеп кору бәясе сметасының 0,5 проценты күләмендә яңа төзелүче һәм үзгәртеп корылучы объектлардан килгән түләүләрнең норматив коэффициентлары;

7/иминлек оешмаларының һәм учреждениеләренең янгыннан саклану буенча янгын чыккан очрак өчен, шул исәптән катнаш иминлектән кергән керемнәреннән мәҗбүри түләүләре;

8/ янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте күрсәтүче түләүле хезмәтләрдән һәм аларның хуҗалык эшчәнлегеннән килгән акчалары;

9/ гамәлдәге законнарда күрсәтелгән бюджеттан тыш башка түләүләр һәм керемнәр.

2. Төрле яклап исәпләнелгән түләүне, шулай ук төзелешнең норматив коэффициентын һәм янгын куркынычсызлыгы максатларында тотылучы иминлек түләүләрен алу һәм бүлү тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгели.

3. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, җирле үзидарә органнары үзләрендә булган акчалар исәбеннән янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте бүлекчәләрен тоту өчен чыгымнарын арттырырга хаклы.

<u>44 статья.</u> Янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәтенә һәм Янгынчыларның республикадагы иректе җәмгыятенә салым ташламалары

Мөстәкыйль нисбәттә торган һәм хокукый зат статусына ия булган янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте, Янгынчыларның республикадагы иректе җәмгыяте, аларның бүлекчәләре, предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр һәм оешмалар уставларында каралган эшчәнлек белән шөгыльләнгәндә гамәлдәге законнар нигезендә табышка һәм мөлкәткә салымнар түләүдән азат ителәләр.

<u>45 статья.</u> Предприятиеләрнең /берләшмәләрнең/, учреждениеләрнең, оешмаларның һәм гражданнарның салым ташламалары

Предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр һәм оешмалар, янгын сүндерүгә, һәлакәттән коткаруның беренчел эшләрен башкаруга тотылучы, шулай ук янгыннан саклануның һәлакәттән коткару хезмәте бүлекчәләре һәм Янгынчыларның республикадагы иректе җәмгыяте заказлары буенча янгыннан саклану һәм һәлакәттән коткару техникасын, коралләр, янгын сүндерү чаралары җитештерүгә һәм сатып алуга тотылучы акчаларга салымнардан һәм җыемнардан азат ителәләр.

Предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар һәм гражданнар тарафыннан "Янгын куркынычсызлыгы" хисабына күчерелүче иганә акчалары гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә салымнардан азат ителәләр.

**8 бүлек. Янгыннарны дәүләт тарафыннан исәпкә алу**

**46 статья. Янгыннарны дәүләт тарафыннан исәпкә алуның тәртибе**

1. Республикадагы янгыннарны дәүләт тарафыннан исәпкә алу Татарстан Республикасының Статистика буенча дәүләт комитеты билгеләгән тәртиптә башкарыла.

2. Предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар, иминлек компанияләре /фирмалары/ һәм гражданнар Дәүләтнең янгын күзәтүе органнары таләбе буенча чыккан янгыннар, алардан килгән турыдан-туры һәм өстәмә зыяннар һәм башка зарарлар турында мәгълүмат бирергә тиеш.

**47 статья. Янгыннарны дәүләт тарафыннан исәпкә алу мәгълүматларын файдалану**

Янгыннарның килеп чыгу сәбәпләрен анализлау һәм гамәлдәге законнар нигезендә тиешле карарлар кабул итү йөзеннән, янгыннарны кисәтерлек чаралар әзерләү һәм килеп туган хәлне вакытында билгели алу өчен, кешеләрнең иминлеген, матди байлыкларның саклануын тәэмин итүгә һәм янгыннарны тиешенчә сүндерү өчен шартлар тудыруга юнәлгән профилактика эшләрен башкару максатларында янгыннарны һәм алардан килгән зыянны исәпкә алу уздырыла.

**48 статья. Янгыннарны дәүләт тарафыннан исәпкә алуның дөреслеге өчен җаваплылык**

Янгыннарны, янгын вакытында зарар күргән затларны һәм аларга

килгән зыянны исәпкә алуның тулылыгы өчен, шулай ук бирелгән хисап мәгълүматларының тулылыгы һәм вакытында тәкъдим ителүе өчен статистик мәгълүматлар биргән предприятиеләр /берләшмәләр/, учреждениеләр, оешмалар, җәмгыятьләр һәм башка хокукый затлар гамәлдәге законнар нигезендә җавап бирә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Хаса 8-